КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2025 ел, 19 июль г.Казань № 530

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында Татарстан Республикасы бюджетыннан бюджетара трансфертлар акчасы исәбеннән финанс ярдәме күрсәтүдән файдалану өчен тәкъдим ителә торган инициативалы проектларны конкурс нигезендә сайлап алуны үткәрү тәртибен, Татарстан Республикасы бюджетыннан бюджетара трансфертлар акчасы исәбеннән финанс ярдәме күрсәтүдән файдалану өчен тәкъдим ителә торган инициативалы проектларны карап тикшерү буенча конкурс комиссиясе турындагы нигезләмәне һәм аның составын раслау хакында» 2021 ел, 5 июль, 545 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы бюджетыннан бюджетара трансфертлар акчасы исәбеннән финанс ярдәме күрсәтүдән файдалану өчен тәкъдим ителә торган инициативалы проектларны карап тикшерү буенча конкурс комиссиясе составына үзгәрешләр кертъ турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында Татарстан Республикасы бюджетыннан бюджетара трансфертлар акчасы исәбеннән финанс ярдәме күрсәтүдән файдалану өчен тәкъдим ителә торган инициативалы проектларны конкурс нигезендә сайлап алуны үткәрү тәртибен, Татарстан Республикасы бюджетыннан бюджетара трансфертлар акчасы исәбеннән финанс ярдәме күрсәтүдән файдалану өчен тәкъдим ителә торган инициативалы

проектларны карап тикшерү буенча конкурс комиссиясе турындагы нигезләмәне һәм аның составын раслау хакында» 2021 ел, 5 июль, 545 нче карары (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 9 август, 783 нче, 2023 ел, 30 март, 380 нче, 2023 ел, 1 ноябрь, 1387 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) белән расланган Татарстан Республикасы бюджетыннан бюджетара трансфертлар акчасы исәбеннән финанс ярдәме күрсәтүдән файдалану өчен тәкъдим ителә торган инициативалы проектларны карап тикшерү буенча конкурс комиссиясе составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

комиссия составыннан Ю.Р.Миңнуллинны, Г.М.Сафинаны, А.М.Фроловны чыгарырга;

комиссия составына кертергә:

| | |
|---|---|
| Сәгыйтова Эльвира Нәзыйф кызын | Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының территориаль үсеш бүлеге башлыгын, конкурс комиссиясе секретарен |
| Жерненков Олег Игоревичны | Татарстан Республикасының яшьләр хөкүмәте рәисен (килешү буенча) |
| Зарипов Раушан Булат улын | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Сәламәтлек саклау, спорт һәм сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру мәсьәләләре идарәсе башлыгын |
| Сабирова Айгөл Азат кызын | Татарстан Республикасы яшьләр эшләре министры урынбасарын |
| Софьина Анастасия Валерьевнаны | Татарстан Республикасының Туристлык буенча дәүләт комитеты рәисе урынбасарын; |

Гарипов Илнур Мәхмүт улы вазыйфасы исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчесенең беренче урынбасарын –Татарстан Республикасы Рәисенең Территорияләр белән эшләү идарәсе башлыгын (килешү буенча)»;

Карпов Родион Михайлович вазыйфасы исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы сәнәгать һәм сәүдә министрының беренче урынбасары».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин